РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
НИЖНЕКАМСКИЙ
ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
пр. Строителей, д. 12, г. Нижнекамск, 423570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА
ШӘҺӘР СОВЕТЫ
Төзүчеләр пр., 12 нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

Тел./факс: (8555) 42-42-66. E-mail: Gorsovet.Nk@tatar.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

2019 елның 13 феврале № 7

**Түбән Кама шәһәр Советының «Физик затлар милкенә салым турында» 2014 елның 20 ноябрендәге 31нче номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Салым кодексының 32 бүлеге, Түбән Кама муниципаль районы Түбән Кама шәһәре муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Түбән Кама шәһәр Советы

**КАРАР БИРӘ:**

1. Түбән Кама шәһәр Советының «Физик затлар милкенә салым турында» (алга таба – «карар») 2014 елның 20 ноябрендәге 31нче номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

карарның 2 пунктындагы 1 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) Түбәндәгеләргә карата 0,1 процент:

- гаражлар һәм машина-урыннар, шул исәптән Россия Федерациясе Салым кодексының 378.2 статьясындагы 7 пункты нигезендә билгеләнә торган исемлеккә кертелгән салым салу объектларында урнашканнар, Россия Федерациясе Салым кодексының 378.2 статьясындагы 10 пунктының икенче абзацында каралган салым салу объектларына карата, шулай ук аларның һәркайсының кадастр бәясе 300 миллион сумнан артып киткән салым салу объектларына карата;

- мәйданы 50 квадрат метрдан артмаган һәм шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару, дача хуҗалыгы, яшелчәчелек, бакчачылык яки шәхси торак төзелеше өчен бирелгән җир кишәрлекләрендә урнашкан хуҗалык каралтылары яки корылмалары;».

2. Карарның 2 пунктындагы 1 пунктча 2 абзацының гамәле (әлеге карар редакциясендә) 2017 елның 1 гыйнварыннан физик затлар мөлкәтенә салым исәпләүгә бәйле хокукый мөнәсәбәтләргә кагыла.

Түбән Кама шәһәре Мэры
вазыйфаларын башкаручы,
Мэр урынбасары Э.Р. Долотказина